# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Үчәлле авыл җирлеге  Үчәлле авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**15.11.2022  ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 15 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2023 елда,  Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

-Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары (тракторчы белән техниканы арендалау, килешү буенча хезмәт өчен түләү, сыешлыкны арендалау, янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм тоту);

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне» бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Үчәлле авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Үчәлле авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш юлларын профильләштерү);

-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне чабу, территорияләрне кипкән агачлардан һәм куаклардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәт күрсәтүе)

РИЗА КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы  катнашучылар исемлегендә 200 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, гражданнар җыенда катнашып тавыш биргән гражданнар  саны - 147 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 145,
«КАРШЫ» позициясе өчен 2 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре- гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2023 елда, Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

-Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары (тракторчы белән техниканы арендалау, килешү буенча хезмәт өчен түләү, сыешлыкны арендалау, янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм тоту);

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне» бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Үчәлле авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Үчәлле авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш юлларын профильләштерү);

-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне чабу, территорияләрне кипкән агачлардан һәм куаклардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәт күрсәтүе)

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина